Татарстан Республикасы Чүпрәле районы
муниципаль бюджет гомуми белем
бирү учреждениесе “Советлар Союзы Герое
Семён Артемьевич Уганин исемендәге
Матак урта гомуми белем
бирү мәктәбе”

# “Мин татарча сөйләшәм!”акциясе конкурсына



# Авторлар:

Халитова Энҗе, Ибраһимова Илвина, Халимова Ләйсән



Мәктәпне яңгыратып кыңгырау чыңлавы ишетелә... Менә Матак урта гомуми белем бирү мәктәбенең киң коридорлары җанланып китә. Укучылар, төркем-төркем булып җыелып, нидер сөйләшә, фикер уртаклаша. Әйе, чыннан да белем йортында дустанә мөнәсәбәт хөкем сөрә.

Без, 14 татар баласы, күрше чуваш авылына йөреп укырга мәҗбүр. Мәктәбебездә барлыгы 75 укучы белем ала. Шуңа да карамастан, яшьтәшләребез белән безнең арада бернинди киртә дә юк. Без инде күптәннән бертуганнар кебек аралашабыз, ә күрше авыл мәктәбе безнең өчен икенче өебез сыман.

Төрле милләт вәкилләре булсак та, киләчәккә омтылышларыбыз, уй-хыялларыбыз бер-берсенә охшаган кебек. Алар белән бергәләшеп белем хәзинәләрен туплыйбыз, төрле сыйныфтан тыш чараларда катнашабыз.

“Мин татарча сөйләшәм” акциясе быел да киң колач җәеп үткәрелә. Һәр ел аны төрлечә үткәрергә, күбрәк катнашучылар җәлеп итәргә тырышабыз. Башкарылган эшебезнең төп максатларының берсе татар телен татарлар арасында гына түгел, башка милләт вәкилләре арасында да популярлаштыру булды.




Туган телем, айлы төнем, якты көнем,
әремнәрдән әче, балдан татлы телем.
Сине саклап калыр өчен, күпме белем
кирәклеген аңладым мин,белдем бүген

Мин татарча сөйләшәм!

# ДУСЛЫК БӘЙРӘМЕ






Татар теле минем, туган телем,

Саклый аны батыр милләтем.

Әби-бабам теле,

Ата-анам теле,

Күңелем тулы аңа хөрмәтем.

Үз телемдә шигырь укыйм,

Үз телемдә сөйли алам.

Туган җирем, туган илем,

Мин бит синнән илһам алам.




Анам теле – телләр теле, милләтемнең бердән бере.
Син булганга без дә исән, син булганга без дә тере.
Татар теле – анам теле, иң борынгы бабам теле,
Буыннардан – буыннарга, күчеп килгән заман теле!


Халкым теле миңа – хаклык теле.
Аннан башка минең телем юк.
Илен сөймәс кенә телен сөймәс,
Иле юкның гына теле юк




Әни кебек газиз күреп, “Туган тел” дип җан атып
Ященик әле дөньясында татар телен яратып!






**Без– татарлар!**
**Шулай диеп белә**
**Безне бөтен дөнья илләре**
**Без– татарлар!**
**Батыр халык дигән**
**Зур данybыз әле сүнмәде.**



"Иелгән башны кылыч кисми", - дигән сүзләрне онытыйк, чөнки иелгән баш зәңгәр күкне дә, якты кояшны да күрми. Тел яшереп, башны иеп яшәү халкыма хас нәрсә түгел! Күтәр башыңны, газиз татарым!



И Ходаем! Алгы көннәрдә дә
Дәрәҗәсез итмә телемне,
Дәрәҗәсез итмә милләтемне,
Дәрәҗәсез итмә дусларымны,
Дәрәҗәсез итмә үземне!

Үз телемдә шигырь укыйм,
Үз телемдә сөйли алам.
Туган илем, туган телем.
Мин бит синнән илһам алам.



Тарала күрмә татарым, чәчелә, сибелә күрмә халкым! Без бердәм булсак кына, хөрмәт һәм бәхет эчендә яшәячәкбез. Таркау булсак та яшәрбез, тик... горур башыбызны түбән и

гомер кичерербе





Туган телем син –
йөрәк җылысы,
Туган телем син –
күңел тойгысы,
Туган телем син –
тарих баскычы,
Туган телем син –
белем ачкычы.






Татар теле минем, туган телем
Изгелекләр тулы бу телдә.
Аны якын күреп, сөйләшүдән сөеп,
Тыя алмый мине беркем дә.



Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.

Туган тел искә төшерде
Шәҗәрә безнең анык:
Без бит хәтта үлгәндә дә,
Газраилне күргәндә дә
Дәшми калмаган халык!

